Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXIV-1**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 13 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 декабрендәге “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” XIV-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге “Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм халкы аз булган авыл торак пунктларына беренче ихтыяҗ товарларын китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында“ 887 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78, 83, 139.1 маддәләре, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.5 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 31 октябрендәге 2854-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 15 декабрендәге “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” XIV-1 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 15 февралендәге № XVI-1 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «604331,67» санын «607357,57» санына алмаштырырга;

1.2) түбәндәге эчтәлектәге 7.1 маддәсен өстәргә:

«7.1маддә

Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - товар (эшләр, хезмәт

күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә түбәндәге очракта бирелә дип билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе поселогыннан 11 километрдан артыграк ераклыкта урнашкан һәм халкы булган торак авыл пунктларына беренче кирәк булган товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарын каплау.»;

1.3) "2017 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан маддәләре, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет ассигнованиеләрен бүлү “ 1 таблицасында 6 нчы кушымтада:

1.3.1) «Милли икътисад» бүлегенең «аталыш» графасында «торак-коммуналь хуҗалык» юлына кадәр «Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр» юлын өстәргә:

- «Рз» графасында «04» цифрларын өстәргә;
- «ПР» графасында «12» цифрларын өстәргә;
- «ЦСР» графасында «9900079010» цифрларын өстәргә;
- «ВР» графасында «800» цифрларын өстәргә;
- «Сумма» графасында «3025,90» цифрларын өстәргә;

1.3.2) «Чыгымнар барлыгы» юлының «Сумма» графасында «604331,67» цифрларын «607357,57» цифрларына алмаштырырга;

1.4) «2017 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 таблицасының 7 нче кушымтасында:

1.4.1) в строке «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты» юлының «Сумма» графасында «38928,97» цифрларын «41954,87» цифрларына алмаштырырга;

1.4.2) «Милли икътисад» юлының «Сумма» графасында «18597,60» цифрларын «21623,50» цифрларына алмаштырырга;

1.4.3) «Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты» бүлегенең «Аталыш» графасында «Торак-коммуналь хуҗалык» юлына хәтле «Милли икътисад өлкәсендәге башка мәсьәләләр» юлын өстәргә:

- «Ведомство» графасында «801» цифрларын өстәргә;
- «Рз» » графасында «04» цифрларын өстәргә;
- «ПР» графасында «12» цифрларын өстәргә;
- «ЦСР» графасында «9900079010» цифрларын өстәргә;
- «ВР» графасында «800» цифрларын өстәргә;
- «Сумма» графасында «3025,90» цифрларын өстәргә;

1.4.4) «Чыгымнар барлыгы» юлының «Сумма» графасында «604331,67» цифрларын «607357,57» цифрларына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль норматив хокукый акт кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев